Татар Танәе урта белем бирү мәктәбе.

# ЯШЬЛЕК

## 12 декабрь– Россия Федерациясе Конституциясе кабул ителгән көн


12 нче декабрь– Россия Федерациясе Конституциясе көне буларак билгеләп үтелә. Быел илебезнең бу төп законы кабул ителүгә 32 ел. Шул уңайдан мәктәбебездә тематик сыйныф сәгатьләре узды. Конституцияне барыбыз да укыйк, хөрмәт итик, белик!



7сыйныф укучысы: Хузина Рәминә

## Кышкы шөгыльләр

Кыш җитүне кем генә яратмый икән аны. Мәсәлән, мин үзем дә кыш фасылын аерым яратам. Саф һавада төрле уеннар уйнавы үзе бер рәхәт һәм файдалы. Безнең үзебезнең хоккей мәйданчыгы бар. Дәресләр тәмамлангannan соң без сыйныфташларыбыз белән шул бозда рәхәтләнеп тимераякта шуабыз. Без анда ярышлар да уздырабыз. Минем иң яраткан уеным тимераякта шуу. Менә безнең авыл малайлары күрше авылга барып икенче мәртәбә инде хоккей уйнап 1 урын яулап кайттылар .Без аларга киләчәктә уңышлар телибез.




7 сыйныф укучысы: Гирфанова Гузәлия

## Мәзәкләр.

-Әни, миңа телевизор карарга ярыймы?
- Ярый, тик кабызма гына.

* * * * * * * * *

Ике кызчык нота өйрәнә.
- “Ми” кайда да, “соль” кайда?
Аларны тыңлап торган малай:
- Ми башыгызда, соль әнә кухня өстәлендә, - ди икән.

* * * * * * * * * *



Каникул алдыннан безнең ЮИД укучылары юл кагыйдәләрен искә төшереп үтәләр. Урамда үзеңне нычек тотарга, юлларда сак булырга, шуталаклардан шуганда игътибарлы булырга.

ЮИД отряды

## Кадерле декабрьдә туучылар!

Уразова Ландыш Фаатовна, Мухаметова Гульфина Мидхатовна

**Сезне чын күңелдән туган көнегез белән котлыйбыз. Сезгә исәнлек саулык, гаилә бәхете телибез.**





Кадерле укытучылар,укучылар сезне якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән котлыйм. Яңа елда яңа уңышлар гына насыйп булсын.

# Һәр көнне игелек кыл...



Һәрбер авылда да сугышта катнашып вафат булган ветераннарга һәйкәл бар .Һәйкәлләр безнең ата-бабаларыбызның рухлары хөрмәтенә , илне саклаучыларны халык онытмасын, безгә тыныч тормыш бүләк иткән кешеләрне һәрчак истә тотсын өчен куелган.Ләкин аның куелуы гына җитми, кешеләр аңа хөрмәт белән карарга тиеш

Тыныч, саф күк йөзе, һәр җиргә дә юл ачык, без нәрсә телибез, шуны эшли алабыз. Без Татар Танае мәктәбе укучылары, үзебезнең авылларда һәйкәлләрне чиста тотарга тырышабыз.

Менә бүген дә хәйкәлне кардан чистарттык, аларга керер өчен юл салдык. Мәктәбебезнең барлык укучылары да әлеге чарада актив катнаштылар.

9 сыйныф укучысы Уразов Салават

Яңа ел алдыннан безнең мәктәбтә .кардан сыннар , сыйныйф бүлмәләрен бизәү конкурсы уза. Һәр эш уникаль, һәркайсына зур хезмәт кертелә. Без аларга олы рәхмәтебезне белдерәбез.





Менә безнең сагынып көткән Яңа ел бәйрәмебез дә килеп җитте. Без рәхәтләнеп биедек, җырладык күңел ачтык.

Башлангыч сыйныф укучылары.

# Кадерле, дуслар!

Барыгызны да якынлашып килүче яңа ел белән котлыйбыз. Киләсе ел бары тик яхшы хәбәрләр,уңышлар гына алып килсен. Бәйрәмегез мөбәрәк, доньяларыбыз тыныч эшләрегез уң булсын. Бәхетле мизгелләр,матур вакыйгалар, саулык-сәламәтлек, шатлык алып килсен. Гаилә бәхетегез учагы гел балкып торсын. Иң изге теләкләр белән,мәктәбенбезнең 11 нче сыйныф укучылары Зайнуллина Алия һәм Уразова Сөмбел.



Баш мөхәррир:
Уразова Сөмбел.
Мөхәррирләр: Зәйнуллина Алия, Рахматуллина Ләйсән
Газета консультанты:
Мостафина Сания
Тел. 2-78-37